СОВЕТ ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Ш. Маннура, д.72 а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ш. Маннур ур., 72 а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-82; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР РЕШЕНИЕ

№ 2-44 15.07.2019ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советының 17.09.2018 ел, 4-35 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставынигезендә,Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 сентябрендәге 4-35 номерлы карары белән расланган«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы»Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:
1.1.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.1. Әлеге статьяда каралган гражданнар җыены торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган яртысыннан артык кеше катнашында хокуклы. Әгәр торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта сайлау хокукына ия булган булса, авыл җирлегеУставы нигезендә гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабулителгәннән соң бер айдан артмаган вакытка этаплап үткәрелә.Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүнең алдагы этапларында катнашмый. Гражданнар җыены карары әгәр аның өчен халык җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә,кабул ителгән дип санала.»;

1.2. 1.6 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«-авыллар арасындагы территорияләрдә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр дә аның

сайлау хокукына ия кешеләре саны 300 дән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы авыл җирлеге стендларында урнаштырырга,Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.
3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олыяз авыл җирлеге башлыгы И.Я.Хаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /И.Я.Хаев/

СОВЕТ ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ОЛУЯЗСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1626001203